| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабря 2025 ел № 13

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 2 нче номерлы карары белән расланган “Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 нчы номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасын мәгълүмати тәэмин итү, анда документлар әйләнешен оештыру чаралары хакында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» гы карары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокурорының 2025 елның 12 декабрендәге № 02-08-02-2025/Прдп376-25 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының “Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы 2017 елның 28 февралендәге 2 номерлы карарына (08.04.2020 ел, №9, 12.05.2020 ел, №11, 06.12.2021 ел, №31, 30.09.2024 ел, №9 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.13 пункты өстәргә:

«4.13. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге региональ яисә муниципаль мәгълүмат системасының рәсми сайтында (булган очракта) федераль законда аларны «Интернет»челтәрендәге бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырмау турында таләп билгеләнгән мәгълүматны һәм документларны урнаштыру рөхсәт ителми».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Кашшапов А.Х.